СӨТ ЭЗЕННӘН

Авыл халкыннан җыйган сөтне ник түккәннәр?

> 2

ӘНИЛӘР ТЕЛӘМИ

Мантудан баш тартуның ахыры аянычлы

> 3

«ЖУРФАК» МӘКТӘБЕ

КФУның кафедра мөдире Васил Гарифуллин белән әңгәмә

> 3

МИЛЛИ АККОРД

«ВТ»ның Татарстанда яшәүче халыкларның милли уен кораллары турында махсус проекты

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 42 (29009) | Шимбә | 25 март | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ГОМЕРЛЕК БҮЛӘК

drkbmzrt.ru

Чәч бөртегеннән дә нечкәрәк җеп белән, микроскоп ярдәмендә 24 тапкыр якынайтып ясалган уникаль операция... Республика балалар клиник хастаханәсе табиблары шушы батырлыгы өчен Россиянең рекордлар китабына кертелде. Биш ел элек катлаулы операция ярдәмендә ике айлык кыз баланың кулын саклап калган алар. Бөтен дөнья күләмендә мондый уникаль операция нибары 14 тапкыр гына ясалган.

Ралинә – Әхмәдуллиннар гаиләсендә көтеп алынган беренче бала.

– Биш ел элек кызыбыз туды. Балабыз сау-сәламәт, барлык күрсәткечләр дә яхшы иде. Әмма берникадәр вакыттан соң аның сул кулының терсәктән бөгелә торган өлешендә шеш пәйда булды. Шунда ук Республика балалар клиник хастаханәсенә бардык. Анда кызыбызны яхшылап тикшерделәр, УЗИ ясадылар. Ахыр чиктә аңа аневризма дигән диагноз куйдылар, – дип искә ала ул мәхшәрле көнне сабыйның әнисе Лилия Әхмәдуллина.

Аневризма, гади тел белән әйткәндә, тукымаларның тартылуы һәм югарыуы аркасында, кан тамырларының тышка бүлтәеп чыгуы дигән сүз. Ул урында капчык сыман шеш пәйда була да янәшәдәге әгъзаларны басып, аларга зыян сала. Шушы шеш аркасында, Ралинәнең кулы да бөгелми башлаган. Сабыйга уникаль операция ясаган Республика балалар клиник хастаханәсенең йөрәк-кан тамырлары хирургиясе бүлеге табибы, медицина фәннәре кандидаты Дмитрий Осипов сүзләренә караганда, зарарланган кулда кан йөреше дә начарланган.

– УЗИ анда тромб барлыгын күрсәтте. Ул теләсә кайсы вакытта өзелергә мөмкин иде. Шуңа күрә, балага кичекмәстән операция ясарга кирәк, дигән карарга килдек, – ди алтын куллы табиб.

Нинди җаваплы адымга баруын да, баланың гомере тулысынча аның кулында икәнен дә бик яхшы аңлаган ул, билгеле. Әмма операция ясамасаң, ахыры тагын да аянычлырак булачак бит. «Баланың кулы бөтенләй эшләүдән туктап, аны кисәргә үк туры киләчәк иде», – ди Дмитрий Осипов.

Операция өч сәгать дәвам иткән. Ул чакта Ралинә нибары 2 ай да 8 көнлек кенә бала була. Дмитрий Осипов сүзләренә караганда, олы кешенең җилкә кан тамыры диаметры 5 миллиметр чамасы, ике айлык баланыкы исә аның яртысы да юк. Шуңа күрә операцияне дә микроскоп белән 24 тапкыр якынайтып ясарга туры килгән. Яралы урынны исә чәч бөртегеннән дә нәзегрәк җеп белән теккәннәр.

Татарстан табиблары ясаган операция уңышлы чыккан. Шулай да тынычланырга ашыкмаган алар. Баланың хәлен, организмдагы үзгәрешләрне өч тәүлек йокламый кизү торып күзәткәннәр.

– Баланың хәле уңайлангач, дөнья күләмендә мондый операцияләрнең кайларда ясалганлыгы белән кызыксындык. Баксаң, аневризма сәбәпле мондый уникаль операция кичергән иң кечкенә балага алты ай булган икән. Бу хәл Америкада булган. Ә без операция ясаган бала нибары ике айлык кына иде. Шуңа күрә Россиянең рекордлар китабына гариза тапшырып карарга булдык. Бер айдан уңай җавап килде. Ралинә аневризмага уникаль операция ясалган иң кечкенә бала буларак рекордлар китабына кертелде. Иң нәзек кан тамыры да – шушы балада. Хирург өчен шаккатмалы хәл бу. Киләчәктә әле Гиннессның рекордлар китабына керү өчен дә гариза тапшырып карыйсыбыз килә, – ди Дмитрий Осипов.

Бу яңалыкка Ралинәнең әти-әнисе дә бик сөенгән. «Шундый алтын куллы хирургка әлегүебезгә шатланып туя алмыйбыз», – ди Лилия Әхмәдуллина.

Бүген Ралинәгә – 5,5 яшь. Яшьтәшләре кебек үк балалар бакчасына йөри, бию белән шөгыльләнә. Биш ел элек булган мәхшәрне дә кулындагы җөй генә искә төшереп тора.

➤2022 елда Республика клиник балалар хастаханәсендә 43 меңнән артык бала дәваланган. Шуларның 3 меңгә якыны – яңа ачылган Балалар онкологиясе, гематология һәм хирургия үзәгендә шифа алган. Балаларның сәламәтлеген кайгырту белән беррәттән, табибларның тормышында гадәттән тыш хәлләр дә еш булып тора.

➤Узган елның декабрендә Республика балалар клиник хастаханәсенең Балалар онкологиясе, гематология һәм хирургия үзәгендә беренче тапкыр сөяк җелеге күзәнәкләрен күчереп утырту буенча тәүге катлаулы операция ясалды. Моңа кадәр мондый операция Мәскәү һәм Санкт-Петербург клиникаларында гына ясала иде. Операция октябрь аенда яман шеш диагнозы белән хастаханәгә эләккән малайга ясалган. Операция уңышлы чыккан.

➤Узган елның сентябрендә Республика балалар клиник хастаханәсе һәм Республика клиник хастаханәсе табиблары 17 яшьлек үсмернең өзелгән кул чугын кабат тоташтырып кую буенча катлаулы операция ясаган. Үсмер, утын ярган чакта, балта белән кулын чабып өзгән. Табиблар егеткә өч катлаулы операция ясаган. Гаҗәп, әмма шуннан соң үсмер егет хәтта кул бармакларын бөгә ала башлаган.

➤2022 елда хастаханә табиблары практикасында тагын бер гадәти булмаган очрак теркәлгән. Алар 12 яшьлек баланың үпкәсеннән үзенең үк тешен алган. Бронхларга баланың тешен алган чакта эләккән булган ул. Соңрак әни кеше баланың күкрәгендә сызгырган сәер тавыш ишетә. Табиблар үпкәне рентгенга төшергәч, баланың бронхларында чит әйбер барлыгын ачыклаган. Баланы Республика балалар клиник хастаханәсенә салалар. Бирәдә бронхлардан тешне ювелирларча алалар. Хәзерге вакытта бала белән барысы да яхшы.



Чистарыну

«Татарстанның чиста урманнары» республика акциясе быел 17 апрельдән 11 сентябрьгә һәм 11 сентябрьдән 11 ноябрьгә кадәр узачак.

Акция Урман хуҗалыгы министрлыгы карамагында уздырыла. Ул урманнарны чүп-чардан, коммуналь калдыклар, чыбык-чабыктан чистарту эшен оештырачак, беседкалар, мәгълүмат такталары, аншлаглар яңартылачак.

Премьер-министр Алексей Песошин башкарма хакимият органнарына бу эшкә кушылу һәм үзләре карамагындагы предприятиеләрдә эшләүчеләрне урман-парклар чистартуга җибәрү бурычын йөкләде. Яшьләр эшләре министрлыгы яшьләрне эшкә җәлеп итәргә, ә муниципалитетлар башлыклары үз районнарында урманнарны чистарту планнарын әзерләргә тиеш.

Исегезгә төшерәбез: республикада яшәүчеләр һәр ел саен «Татарстанның чиста урманнары» акциясендә, «Хәтер бакчасы» халыкара акциясе һәм «Урманны саклыйбыз» Бөтенроссия акциясендә катнашып килә. Алар барышында 2 миллионнан артыграк агач үсентесе утыртыла. 10 мең куб. метр чамасы күләмендә чүп-чар җыеп алына.

Сөенечле кимү

Февраль аенда Татарстанда инфляция акрынаеп, 10,7 процент дәрәҗәсендә туктап калган (гыйнвар аенда – 11,6%). Идел буе федераль округы һәм тулаем Россия буенча кимрәк күрсәткеч бу. Үзәк банк хәбәр иткәнчә, бәяләргә асылда кайбер авыл хуҗалыгы культураларыннан мул уңыш җыеп алу, озак кулланылыштагы товарларга ихтыяҗның аз булуы йогынты ясаган.

Әйтик, кышның соңгы аенда азык-төлек бәясе 10,1 процентка диярлек кимегән. Бу узган елда ашлык, шикәр чөгендере һәм башка культураларның әйбәт кенә уңыш бирүенә бәйле. Нәтиҗәдә токмач, үсемлек мае һәм шикәр бәясе төшкән. Ярма һәм кузаклылар хакы да, гыйнварда үскәннән соң, берникадәр кимегән.

Февраль аенда сәнәгать товарлары бәясе 10,3 процентка төшкән. Кер юу машиналары, суыткыч, кыска дулкынлы мич һәм башка көнкүреш техникасы да берникадәр арзанайган. Сәбәбе – ихтыяҗның аз булуы. Шул ук вакытта кибетләрдә электр товарлары (параллель импорт хисабына) арткан. Смартфоннар, чыбыксыз колакчын һәм телевизорлар бәясе дә шул сәбәпле төшкән.

Үзәк банк фаразларына караганда, якындагы айларда Россиядә инфляция күләме тагын 4 процентка кимергә мөмкин.

Багышлый башлыйлар

Яңа уку елында Татарстанда балалар һәм үсмерләрне «Алдынгылар хәрәкәте»нә багышлау тантаналары башланачак. Хәрәкәтнең республикадагы җитәкчесе Тимур Сөләйманов «Татар-информ» агентлыгына әйтүенчә, багышлау тантаналары, мактаулы кунаклар катнашында, яшьләр үзәкләре, балалар сәнгать мәктәпләре кебек мәйданчыкларда үткәрелергә мөмкин. «Балалар һәм яшьләр өчен бик кызыклы, истә калырлык булачак бу», – дигән ул. Хәзерге вакытта хәрәкәтнең атрибутикасы эшләнелә. Аны булдыруда яшьләр үзләре үк ярдәм итә.

Киләсе уку елы башында республика мәктәпләрендә тәрбия эше һәм балалар оешмалары белән хезмәттәшлек итү буенча киңәшчеләр дә пәйда булачак. Тимур Сөләйманов сүзләренә караганда, алар директорлар һәм тәрбия эше буенча директор урынбасарларына ярдәм итәчәк. Киңәшчеләр мәктәпләрдә хәрәкәтне үстерү белән турыдан-туры шөгыльләнәчәк.

Чир кермәсен

Татарстанга терлекләр өчен куркыныч тилчә (ящур) авыруы кермәсен дисәк, Казахстаннан һәм аның янәшәсендәге төбәкләрдән мал алып кайтмаска кирәк. Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасары Габделхак Мотыйгуллин шундый фикердә.

Аның әйтүенчә, тилчә белән дуңгыз, сарык, болан, хәтта кешеләр дә авырый. Чирнең инкубация чоры – 14 көнгә кадәр. Бик тиз тарала. Авыру терлек янына чиста кием белән кергән очракта да, вирус киемдә 40 көннән артык саклана.

Габделхак Мотыйгуллин сүзләренә караганда, тилчә авыруы Казахстанда 2021 елның икенче яртысыннан бирле тарала икән.

Бу турыда фермерлар чаң какса да, ни сәбәпледер рәсми төстә хәбәр ителмәгән. Авыру Оренбург өлкәсенә килеп җиткәч кенә рәсми игълан иткәннәр. Безнең республикага да бу җәһәттән куркыныч яный. Авыру Татарстанда соңгы тапкыр 1960 нчы елларда теркәлгән.

Шуңа күрә белгеч Казахстан чигендәге Оренбург, Самара, Саратов һәм Чиләбе өлкәләреннән терлекләр алып кайтмаска киңәш итә. Моннан тыш авыл җирлеге башлыкларына һәм районнардагы мал табибларына машиналарыннан терлек, кош-корт сатып йөрүче арадашчыларга аеруча игътибарлы булырга кирәклеген искәртә.

Яшәеш

Тәртип үзгәрә

Татарстанда 25 апрельдән 14 майга кадәр янгынга каршы махсус режим кертеләчәк. Урманнарда бу режим 15 апрельдән башланачак. Көннәрнең җылы торуы янгын куркынычын тудыра.

1 марттан йорт янәшәсендә учак ягып ризык әзерләү, коры үлән яндыру җәһәтеннән дә үзгәрешләр бар. Шулай ук янгын сүндерүгә керү юлларында комачау итүчеләргә дә моннан соң итәкләрен җыясы. Бу хакта «Татар-информ»да узган очрашуда Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эшенең норматив-техник идарәсе бүлеге җитәкчесе Евгений Врачев сөйләде.

– 2023 елның 1 мартыннан Татарстанда һәм бөтен Россия буенча янгынга каршы режим кагыйдәләрен үзгәртү үз көченә керә. Хәзер мангалларны һәм ризык пешерә торган җайланмаларны корылмалардан кимендә 5 метр ераклыкта урнаштырырга кирәк булачак. Учак ягу тыелмый, әмма куркынычсызлык таләпләрен үтәү мәҗбүри. Үлән, яфрак һәм чүп-чарны биналардан кимендә 15 метр ераклыкта яндырырга, ә чүп-чар тутырган савытны 7,5 метр ераклыкта урнаштырырга кирәк. Түбәләрдә, балконнарда пиротехника куллану тыела. Шул исәптән бенгаль утларын да яндырырга ярамый, – ди Евгений Врачев.

Урманнарда янгынга каршы махсус режим кертелгәч, шырпыны сызмый тору хәерле. Быелгы язның иртәрәк килүен дә күз уңында тотып, белгечләр халыкның сак булуын сорый. Республикада урманнарга якын урнашкан 116 авыл, 75 бакча, балалар өчен 84 ял һәм сәламәтләндерү оешмалары тирәсендә учак ягу, чүп-чарны яндыру, ачык утта ризык әзерләү бөтенләй тыела. Урман белән торак пункт арасында кимендә 10 метр минераллаштырылган полоса булу кирәк. Янгын чыгу куркынычы булмаган җирләрдә дә тиешле кагыйдәләр үтәлергә тиеш.



pixabay.com

– Яңа кагыйдәләр кергәч, подвалда һәм аның тәрәзәләре аша авария вакытында чыгу каралмаган булса, анда рәшәткәләр кую тыела. Янгын сүндерүгә комачау итүче киртәләр булырга тиеш түгел. Эвакуация юллары да ачык булсын, – ди Евгений Врачев.

Белгечләр һәр гаиләдә янгын турында хәбәр бирүче җайланма булсын иде дигән фикердә. Ник дигәндә, күп кенә очракларда нәкъ менә шушы җайланма аркасында уттан исән-имин котылган кешеләр бар. Быел да бу максатларда күпбалалы гаиләләргә шушы җайланманы урнаштыру өчен Татарстан бюджетыннан 127 миллион сум акча бүлеп биреләчәк. Республикада яшәүче 1600 гаиләгә бу җайланма бушлай куела. Әгәр бакча йорты тору өчен яраклы дип саналса, аңа да янгын хакында хәбәр бирүче җайланма куелырга тиеш.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Янгынга каршы режим кертелгән вакытта тәртип бозучы гади кешеләргә – 10 меңнән 20 меңгә кадәр, вазыйфаи затларга – 30 меңнән 60 меңгә кадәр, эшмәкәрләргә – 60 меңнән 80 меңгә, юридик затларга 400 меңнән 800 мең сумга кадәр штраф каралган.

Сүзгә-сүз

Наталья КОСТЕНКО, Россия Дәүләт Думасы депутаты:

Илдә быел да балалар һәм туристик кешбэк программасын гамәлдә калдырырга кирәк. Дөрес, аның шартларын үзгәртү зарур: ташламаны алдагы еллардагы кебек үк биш йолдызлы кунакханәгә юллама сатып алучыларга түгел, ә балалар ял лагерьларына, шифаханәләргә, аерым төбәкләргә ял итәргә баручыларга гына бирергә кирәк. Без әлеге мәсьәләне хәл итүне көн кадагында тотачакбыз.

(«Парламентская газета»дан)

РОССИЯДӘ – ЭШСЕЗЛӘР

2018 ел	3,7 млн
2019 ел	3,5 млн
2020 ел	4,4 млн
2021 ел	3,2 млн
2022 ел	2,8 млн

Росстат мәгълүматларына нигезләнеп

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Кытайлар кысса кулың...

Узып баручы атнаның Россиягә караган төп вакыйгасы дип, әлбәттә инде, Кытай лидеры Си Цзиньпинның Мәскәүгә ике көнлек визитын атарга буладыр. КХР җитәкчесе Россия башкаласына нинди максатлар белән килгән? Визит ике ил арасындагы сәүдә-икътисад багланышларына яңа импульс өстәрме? Көнчыгыш күрше Украина кризисы тәмамлануын ихластан телиме? Көнбатыш белән тарткалашта Россия Күк асты илен үзенең стратегик аркадашы итеп күрә башлар сәбәпләр зурмы?

Баштан ук шунысын әйтәсе килә: кешелек XXI гасырда яшәсә дә, үзара мөнәсәбәтләрдә дәүләтләр әле дә берберсенең беләгенә, ягъни икътисадый һәм хәрби көченә, территориаль зурлыгына, башкаларга булган йогынтысына карап эш йөртә, исәпләшә. Кечерәкләргә ул яктан кыенрак. Җәберләмәгәндә дә, ниндидер Финляндия ягына карап: «Сездә – җыйнак һәм тыйнак илдә гражданнарның тормыш сыйфаты үтә дә югары, халкыгызны оҗмахта яшәтәсез, шуңа да хөрмәтебез чиксез, без дә, минминлекләребездән баш тартып, сездәй булырга тырышачакбыз», – дип әйтү халыкара багланышларда әле көтелми. Олылар, юан мускуллылар халыкара хәлләрдә һаман да доминант һәм хөкемдарлар булып кала.

Кытай белән Россия дә дөньяви «һава торышы»н билгеләүчеләр арасында. Кытай, белүебезчә, бүгенге дөньяның гомумән дә икенче икътисады. Узган 2022 ел илнең эчке тулай продукты (ВВП) 18 триллион долларлык булган. Икътисадый куәт ягыннан 10 нчы урындагы Россиядән (эчке тулай продукты – 2 триллион доллар) ул 9 тапкыр көчлерәк. Тик кемнәрдер Россияне Кытайның кече партнеры, дип атауга да карамастан, без дә төшеп калганнардан түгелбез. Биләмәләребез кытайларныкыннан ике тапкыр диярлек зур. Ходай файдалы казылмаларны да өеп биргән. Ул гынамы, атом арсеналыбыз да алар белән чагыштыра торган түгел. Халык саны дигәндә, Кытайда ул 1,4 млрд тирәсе, ягъни бездәгедән тугыз-ун тапкыр артык. Һәм инде җан башына туры килгән эчке тулай продукт дигәндә, ике күрше дә бер тирәдәрәк кайнаша. БМО, Халыкара валюта фонды, Бөтендөнья банкы бергәләшеп төзегән рейтингта һәр ике илдә дә аның күләме – 12 мең доллар тирәсе. (Финляндиядә ул санның 49040 доллар икәнен искәртик.)

Төп сүзгә – визитка күчик. Россиядәге рәсми мәгълүмат чаралары аны тарихи дип бәяләде. Си Цзиньпинның дәүләт лидеры постына өченче тапкыр сайланганнан соң, атна-ун көн узуга Россиягә килүе дә очрашуга аерым дәрәҗә өсти кебек. Сайлау алдыннан Кытай Украина конфликтын җайлау җәһәтеннән тулы бер программа белән чыккан иде. Визит максатларының берсе – шуны ничек тә булса хәрәкәткә китерү, дисә, артык хаталанмабыз. Тынычлык урнаштыруда арадашчылык саваплы гамәл булудан гына түгел. Конфликт Кытайдан еракта барса да, анда атом арсеналы хәйран зур булган дәүләтнең катнашуы, Көнбатышның Украинага масштаблы перманент ярдәме кытайларны борчымый калмый.

Әмма визитның төп сәбәбе башкада кебек. Украина төене кытайларны борчыса да, ул хәл аларга яхшы дивидендлар да китереп тора. Узган ел дәвамында, билгеле сәбәпләр аркасында, Россия, аның икътисадый мәнфәгатьләре тулысы белән диярлек Көнчыгыш тарафка борылды. Ә анда Кытайдан да зур, аннан да куәтле, табигый ресурслар сатып алу дигәндә, аннан да олы базар юк. Җитмәсә, ул безнең күрше дә. Хәзерге вазгыятьтә алар белән якынаймый чара юк. Кытай моны бик яхшы аңлый, хәлдән йөз процент файдаланып калырга тырыша, һәм, әлбәттә инде, якты чырай ката. Нефть, газ агымнары ул якка инде ныклап борылды да. Тик, мәгълүм ки, сату бәяләре гел башка. Без әлегә Күк асты иле өчен «ташламалы ягулык салу станциясе» ролендә булырга мәҗбүр. Бу кытайларга, акрыная барган үсеш темпларын тизләтү өчен, менә дигән импульс. Гомумән, көнчыгыш күршебезгә үз икътисадын очсызлы чимал белән никадәр озаграк туендырса, шулкадәр яхшы. Ай саен күренеп, якты елмаеп, кул кысып китәргә була. Россиягә исә, чимал базары гына түгел, хәзерге хәлләрдә стратегик аркадаш та бик кирәк. Ярымсимволик кимәлдә булса да. Кытайга да Россия картасын уйнау отышсыз түгел.

Тик шунысын да ассызыклыйк: Кытайның дөньядагы киеренке хәлләргә, «кайнар нокта»ларга карата үз-үзен тотышы һәрчак сак һәм үзенчәлекле. «Йомшак көч» («мягкая сила») дигән төшенчә нәкъ менә аларга туры килә. Аларда беренче урында – һәрдаим икътисад һәм эчке сәясәт. Тышкы сәясәт аннан соң. Гомумән, Кытайны нинди дә булса экспансиядә, кирәкмәгән җиргә борын тыгуда гаепләү моңа кадәр авыр булды. Ул дөньяны үзендә җитештерелгән товарлар белән яулый. Шул ук АКШ белән, дуслык гел сизелмәсә дә, товар әйләнеше астрономик суммада – 1 трлн долларга якын. Европа илләре дигәндә дә, сан шуңа якынлаша. Табигый ки, мондый хәлләрдә Кытай безгә хәрби-стратегик аркадаш булып, кораллар белән ярдәм итә алмый. Андыйга китсә, үзара сәүдә әйләнеше тиз арада кимү ягына юнәләчәк. Россия дигәндә, алыш-биреш күләме әлегә 200 млрд долларга тулмый. Цзиньпин Михаил Мишустин белән очрашканда, яклар киләчәктә нәкъ шул санга юнәлеш тоту турында килеште.

Табигый ресурслардан кала Кытай өчен тагын да бер күктән ишелгән отышлы өлкә – бездә бушаган җиңел автомобиль сату мәйданнары. Япония, Корея, АКШ, Европа автомобиль брендлары Россиядән китте. Алардан калган бушлыкны 10–15тән арткан чин маркалары тутырыр дип көтелә. Башка вариантлар – алар моңарчы ясап килгәнне үз исемебез астында чыгару да булачак. Киң рекламаланган яңа «Москвич» нәкъ менә исеме үзгәртелгән, мультимедиясе русчалаштырылган, Кытай үзендә җитештереп килгән JAC JS4 автомобиле...

Визит игълан ителүгә, күпләр аннан сенсацияле нәтиҗәләр көткән иде. Тик мәгълүмат чаралары Кытай делегациясенең визит барышындагы төрле купшылыклардан баш тартуы хакында белдерүгә, сенсация көтүләр суынды. Си Цзиньпин каршына хәтта икмәк белән тоз тоткан милли киемнәрдәге чибәр кызлар да чыкмады. Кытай дәүләте рәисен каршыларга дәүләт җитәкчесе үзе, йә булмаса, илдә рангы буенча икенче кеше саналган Премьер-министр түгел, ә халык юньләп белеп тә бетермәгән вице-премьер Дмитрий Чернышенконың килүе дә кунакның дәүләт визитыннан бигрәк, эш визиты белән килүе турында сөйләде кебек. Дөньялар тыныч булмаганда, чыннан да, нинди купшылык, нинди тантана инде ул?!

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

ТАТАРСТАНДА СЫНАЛА

Хөкүмәт йортында «Татнефтехиминвест-холдинг» җәмгыяте Директорлар советы утырышы узды.

tatarstan.ru

Гадәттәгечә, Татарстан Рәисен төрле проектлар белән кызыксындырырга тырыштылар. Нигездә, инновацион проектлар нефть-газ химиясе тармагына бәйле иде. Эретеп ябыштыру өчен яңа технологияләр, җиһазларның яшерен кимчелекләрен табу җайланмалары – кайсыларын нинди тармакта кулланырга мөмкин?

Казанның Завойский исемендәге физика-техника институтының лабораториясе мөдире Вадим Семашко оптоакустик технологияләр турында сөйләде. Алар ярдәмендә җиһазлардагы яшерен кимчелекләрне табарга мөмкин икән. Контактлы лазерлы-ультратавыш дефектоскопиясе гадәти ультратавыш контроленнән 10 мәртәбә нәтиҗәлерәк. Институтта мондый приборлар булдыру базарның 15 процентын биләргә мөмкинлек бирәчәк дип саныйлар. Моннан тыш, оптоакустик томография медицина тармагында да кулланылыш табар иде. Ул яман шеш һәм йөрәк-кан тамырлары авыруларын башлангыч стадиядә табарга мөмкинлек бирә. Әлеге җайланманы әзерләгәндә бары тик үзебездә җитештерелгән материаллар гына кулланылачак, дип ассызыкладылар.

Әлеге проектка «Татнефтехиминвест-холдинг» җәмгыятенең генераль директоры Рафинат Яруллин да бәя бирде.

– Композитлар кулланыла торган барлык тармаклар өчен дә кызыклы проект дип саныйм. Аеруча медицина өчен үзенчәлекле, – диде ул.

Татарстан Рәисе исә әлеге уңайдан «түгәрәк өстәл» җыеп, бу хакта җентекләбрәк сөйләшергә кушты. Әлбәттә, медицина белгечләрен, сәнәгать предприятиеләре вәкилләрен дә чакырып.

Дулкын белән эшкәртү технологиясе хакында Мәскәүдән Алексей Огневский сөйләде. Әлеге технология җепселләр җитештергәндә химик процессларны тизләтә һәм үз чиратында җитештерү бәясен дә киметергә мөмкинлек бирә. Аны мамык, җеп, композит материаллар чыгару өчен кулланып булыр иде. Рөстәм Миңнеханов та мондый проектларга республикада кызыксыну булуын искәртте.

Республиканың нефть-газ предприятиеләрен насос-компрессор җиһазлары белән тәэмин итү турында «ОКБ Африкантов» җәмгыятеннән Илья Коробов сөйләде. Сүз сыекландырылган углеводород газларын (СУГ) суырту, югары басымлы, суга батыра торган криоген насослар турында бара.

– Үсеш өчен мөмкинлекләр булган юнәлеш бу. Чит ил җитештерүчеләреннән калган буш урыннарны алырга тырышабыз, – диде Илья Коробов. – Герметик насослар ясау – СИБУРның сынау проекты. Алар белән килешү төзелде. «Татнефть»кә исә насослар җибәрү турында тәкъдим ясалды.

Автомат иминиятләштерү. Санкт-Петербургта эре предприятиеләрне иминиятләштерүнең шундый ысулын уйлап тапканнар. Бу хакта «InsurTech» платформасы генераль директоры Игорь Кононов хәбәр итте. Веб-хезмәт иминият килешүләрен рәсмиләштерә, акча түләүне автоматлаштыра, документлар әйләнешен алып барырга булыша. Татарстан Рәисе Иннополиска җыелып, бу хакта предприятие вәкилләре өчен семинар уздырырга тәкъдим итте.

Торбаларны эретеп ябыштыру, кисү һәм төзү өчен заманча технологияләрне «ТЕХНОТРОН» эретеп ябыштыру җиһазлары заводының маркетинг һәм сату буенча директор урынбасары Олег Гецкин тәкъдим итте. Рөстәм Миңнеханов билгеләп үткәнчә, бүген Татарстанда торак-коммуналь хуҗалык тармагын яңарту буенча зур программа гамәлгә ашырыла. Шуңа күрә эретеп ябыштыру өчен аппаратларга ихтыяҗ аеруча зур.

ОЗАК КӨТӘСЕ КАЛМАДЫ

Татарстан районнарындагы тормыш сыйфатын тагын да җентекләбрәк тикшерә башлаганнар. Республикадагы иң яхшы һәм аксап килүче муниципаль берәмлекләрне ачыкларга ярдәм итүче социаль-икътисадый рейтингка үзгәрешләр кергән. Район башлыкларына нәрсәгә игътибар итәргә?

Билгеле булганча, республика районнары һәм шәһәрләренең социаль-икътисадый үсеш рейтингын Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов кушуы буенча, 2010 елдан бирле республиканың Икътисад министрлыгы әзерли. Исемлек 45 баскычтан тора. Биредә 43 районнан тыш, Казан һәм Чаллы шәһәрләре дә бар. Моңа кадәр рейтингны төзегәндә төбәктәге уртача хезмәт хакы, кулланышка тапшырган торак күләме, төп капиталга инвестицияләр, салым һәм салымга бәйле булмаган керемнәр, эшсезлек дәрәҗәсе кебек тормышының төрле өлкәләренә караган гомуми күрсәткечләр исәпкә алынды.

– Социаль-икътисадый рейтинг үзенең ни дәрәҗәдә әһәмиятле булуын раслап күрсәтте инде. Быел районнардагы тормыш сыйфатын билгеләүгә бәйле бу эшкә үзгәрешләр дә керде. Алга таба районнар исемлеген төзегәндә абсолют күрсәткечләрдән баш тартып, чагыштырмача булган 15 күрсәткеч исәпкә алыначак, – диде Татарстан икътисад министры урынбасары Роман Әмирханов «Татар-информ» агентлыгында узган матбугат очрашуында.

Аның сүзләренчә, яңа методика төзүдә республиканың барлык министрлыклары һәм ведомстволары, шулай ук район хакимиятләре үзләре дә катнашкан. Барлыгы 35 тәкъдим килгән. Яңа күрсәткечләр арасында бер гектар сөрүлек җиренә туры килгән тулаем авыл хуҗалыгы продукциясе, җан башына туры килгән кулланылышка тапшырылган торак мәйданы, халыкның реаль акчалата кереме үсеше, сәнәгать җитештерү индексы кебек күрсәткечләр исәпкә алыначак. Зуррак саннар белән дә эшләячәкләр. Моңа кадәр рейтингны ай саен яңартып торсалар, хәзер аны өч айга бер тапкыр гына игълан итәчәкләр. Озак көтәсе калмады. «Бу елның тәүге рейтингы 20 апрельдә билгеле булачак», – диде Роман Әмирханов.

Балык Бистәсендә яшәүчеләр Әлмәт халкы белән көндәшлек итә алмый бит, дип рейтингның дөреслеген шик астына да куеп карады журналистлар. Шунысы да бар: исемлекнең иң югары баскычында елдан-ел бер үк муниципаль берәмлекләр кереп урнаша. Төртмәле сорауларга җавап бер булды: социаль-икътисадый рейтинг «глава»ларга үпкә белдереп утырырга сәбәп түгел.

– Әлеге исемлек муниципаль берәмлек җитәкчеләре өчен эшләнә дә инде. Бу – аларның өстәл кәгазе. Кайсы юнәлештә эшне көчәйтергә мөмкин икәнен күрсеннәр, вазгыятьне аңласыннар. Социаль-икътисадый рейтинг көндәлек эш булырга тиеш. Исемлеккә чирек елга бер тапкыр гына күз салып, уңышка ирешеп булмый, әлбәттә, – диде министр урынбасары.

«ВТ» узган ел нәтиҗәләре буенча гомуми рейтингка нигезләнеп, алда баручы һәм артта калган районнар турында мәгълүмат биргәч, безгә кырын караучылар да булды. Югыйсә без төзегән исемлек түгел. «Апрель азагында игълан ителгән рейтингта кискен үзгәрешләр булырмы?» – дигән сорауга министр урынбасары җавап бирмәде. Сабыр итәргә кушып, рейтингның элек тә, хәзер дә гадел булуын гына белдерде. Без әйтмәдек!

Эльвира ВӘЛИЕВА

Дус яшәүгә ни җитә!

Милләтара тынычлык һәм татулык, халыкларның этномәдәни үсеше һәм милли мәгарифне үстерү программалары. Биектау районында узган Татарстан Халыклары ассамблеясы Советы Президиумының күчмә утырышында әнә шул мәсьәләләр хакында фикер алыштылар.

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, нәкъ менә районнар милләтара мөнәсәбәтләрне саклауда һәм ныгытуда әйдәп баручы роль уйный.

– Районнарга чыгып, без халык арасында, халык белән бергә мөһим мәсьәләләрне чишәбез. Биектау районында этномәдәни үсешкә, туган телләрне өйрәнүгә, яшьләр аңында милләтара һәм динара тынычлык, татулык принципларын формалаштыруга зур игътибар бирелә. Бу Татарстан кебек күпмилләтле республика өчен бик мөһим, – ди Фәрит Мөхәммәтшин.

Парламент башлыгы Татарстан Халыклар ассамблеясының республикада яшәүче төрле милләт вәкилләренең телләрен өйрәнү, милли мәдәниятне һәм традицияләрне үстерү өлкәсендә системалы эш алып баруын билгеләп үтте.

– Шунысы сөенечле: республикада төрле милләт вәкилләре арасында аңлашылмаучанлык юк. Һәр халыкның мәдәниятен һәм традицияләрен саклау, үстерү өчен барлык шартлар тудырылган. Республикада узган күп кенә чаралар күрше төбәкләрдә дә зур кызыксыну уята. Безгә бертуктаусыз төрле делегацияләр килә, эш формаларыбызны өйрәнә. Моны бәяләмичә калдырырга ярамый. Кайвакыт без көндәлек эштә шулай булырга тиеш дип уйлыйбыз. Әмма барлык субъектлар да бу зур бурычның мөһимлеген аңлап бетерми, – диде ул.

Биектау районында тынычлыкта һәм татулыкта утыздан артык милләт вәкиле яши. Татарлар – 67,2, руслар – 31,8, башка милләтләр 1 процентны тәшкил итә.

– Һәр милләтнең үз тарихы, теле, гореф-гадәтләре бар. Әлеге үзенчәлекләрне онытмыйча, үзара ихтирамлы, илебезнең бердәм халкы булып яшәргә омтылсак иде, – диде Биектау районы башлыгы Равил Хисаметдинов.

Милләтнең үсешен милли мәгарифтән башка күзаллау мөмкин түгел. Районадагы мәгариф оешмаларының эш тәҗрибәсе белән Биектау районы Башкарма комитетының милли мәгариф бүлеге методисты Сәлимә Юнысова таныштырды. Райондагы 16 татар телле мәктәпкәчә белем бирү оешмасына 395 татар баласы йөри. Гомуми белем бирү учреждениеләрендә барлыгы 7391 укучы белем ала. Шуларның 4331е – татарлар.

«Туган телне балачактан ук, гаиләдә, бакчада өйрәнә башлау уңай нәтиҗәләр бирә», – ди Сәлимә Юнысова. Туган телне һәм гореф-гадәтләрне саклап калуда үрнәк булырлык оешмалар итеп ул Ямаширмә авылы урта мәктәбе һәм «Йолдыз» балалар бакчасын китерде. Бу белем оешмалары базасында милли үзәк оештырылган.

Телен зурлаган әти-әни генә туган телен хөрмәт иткән бала тәрбияли ала. Милли мәгариф бүлеге методисты, үз чыгышын тәмамлап, әнә шулай диде.

– Мөһим бурычыбыз – әти-әниләр белән эшне дөрес итеп оештыру. Ел саен татар телле ата-аналар өчен конференция үткәрелә, биредә әти-әниләр рус мохитендә туган телдә белем һәм тәрбия бирү турында үз тәҗрибәләре турында сөйлиләр, фикер алышалар. Милли рухта тәрбияләнеп үскән яшьләребез киләчәктә тормышта үз урыннарын табып, җәмгыятьнең тәрбияле, зыялы шәхесләре булып яшәрләр, илебез үсешенә мөһим өлеш кертерләр дип ышанасы килә, – диде Сәлимә Юнысова.

Ләйсән САФИНА

СӨТ КАЯ АККАН?

Борчыган мәсьәлә

Берничә көн элек Апас районының Зур Болгаер авылында күңелсез хәл килеп чыккан. Халыктан җыелган сөтне, антибиотик табылды, дип кайтарып түккәннәр. Тик бу эшне халыкның күз алдында эшләмәгәннәр, төшереп, видеосын гына таратканнар, шуңа моңа ышанмыйлар.

– Без хуҗалыкта җиде сыер асрыйбыз. Ул көнне мин 3 савым сөтен тапшырдым. Барысы бергә 138 литр иде, – диде безгә Зур Болгаер авылында яшәүче Алсу Хөсәенова. – Сөт җыючы егетләр безне алдан кисәтмичә, сөтне җиргә түккәннәр. «Ватсап»тагы төркемгә: «Сөттә антибиотик табылды. Акча түләнмәячәк», – дип видео гына җибәрделәр. Ләкин, видеодан күренгәнчә, ул сөт түгел, су бит. Сөт андый булмый ул. Анда майлылыкның әсәре дә юк. Авыл халкын шулай мыскылларга кирәкме? – диде ул.

Ул видеоны безгә дә җибәрделәр. Чыннан да, мичкәдән аккан сыеклык сөткә охшамаган. Мичкә юган су дисәк, дөресрәк булыр. Чын сөт кая киткән соң?

– Моны без халыкны мыскыллау дип кабул иттек, – ди Владимир Скворцов. – Сөтегезне түктек, акча түләнмәячәк, диделәр. Ни өчен кире таратмадылар аны? Берсе дә авыл халкы өчен тырышмый. Ул терлекләрне карарга күпме хезмәт куела. Азыгын аласы бар. Кибеттә сөт 80 сум тора, авылныкы – 19!

Алсу ханым әйтүенчә, моңа кадәр дә сөттә антибиотик табылган очраклар булган. Андый вакытларда гадәттә группага: «Сөтләрегезне нишләтик? Алып кайтыйкмы?» – дип сорый торган булганнар.

– Сөтне түгәргә дип уйлаган очракта да, алдан сорарга була иде бит. Мин, мәсәлән, кайтарткан булыр идем. Хуҗалыгымда 70ләп сарыгым бар. Шуларга эчергән булыр идем. Сөт бәясе болай да төшеп бетте бит. 21 сумнан түлиләр иде, мартның икенче яртысына 19 сумнан түләячәкләр, диләр. Анысына да сабыр иттек, ләкин бу хәл бар халыкның ачуын чыгарды. Бер авылдашым кичә хурланып елады. Бер сыер сава ул. Төп кереме – сөттән, – диде Алсу Хөсәенова.

Хәлне ачыклар өчен районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Радик Гыйсмәтов белән элемтәгә кердек.

– Беренчедән, видеода сөт түгел, мичкә юган су ул. Икенчедән, авыл советына шалтыратып белешкән идем, сөт җыю машинасы безнеке түгел, дип әйттеләр. Авыл исемен Зур Болгаер дип куйсалар да, дөреслеккә туры килми. Сөт җыючы да шуны ук әйткән, – дип аңлатты җитәкче.

Тик берникадәр вакыттан соң ул үзе кабат шалтыратты.

–Ул видеода, чыннан да, Болгаер авылындагы хәл булган икән. Машина да авылда сөт җыючыныкы. Ул халыкның сөтен түкмәгән, аларны куркытыр өчен генә эшләгән. Ни өчен шулай эшләвен әйтә алмыйм, – диде идарә башлыгы.



Интернетта Апас районыннан әнә шундый видео таралды.

Сөт җыючы Илфирга шалтыратып, кызыксындырган сорауларыбызны аңа да бирәсебез килгән иде. Тик ул безнең рәсми хат юллавыбызны сорады. Моңа кадәр сөт җыючы белән рәсми хатлар аша аралашкан булмаса да, анысын да эшләргә ризалаштык. Тик хат җибәрүгә өч көн узса да, үзеннән җавап ала алмадык. Җавап биргән очракта, әлеге темага кабат әйләнеп кайтырбыз.

Исегезгә төшереп узыйк: узган саннарда Олы Борындык авылы халкы чакыруы буенча шулай ук Апас районына кайткан идек. Ул чакта халык сөт бәясенең түбән булуыннан зарланды. Кызганыч, вазгыять яхшы якка үзгәрмәде. Бөтен республика буенча сөт бәяләре кинәт кими башлады. Әйтик, Апас районында ел башыннан халыкка сөт өчен түләү бәясе 6–7 сумга төште.

– Сөт бәясе бездән генә тормый, – диде Радик Гыйсмәтов, әлеге мәсьәләгә кабаттан кайтып. – Заводлар бәяне шулай куя. Шушы көннәрдә идарә башлыклары, завод җитәкчеләре, министрлык вәкилләре белән сөйләшү булган иде. Анда катнашучы бер кеше: «23 ел буе эшләү тарихында бервакытта да заводтан сөтне кире кайтарганнары юк иде. Сөт кирәкми заводларга», – дип сөйләде. Сәбәпләрен Белоруссиядән коры сөт керү белән дә, халыкның сатып алу дәрәҗәсе түбән булу белән дә бәйләп аңлаталар.

Ә сөт түктек дип, су агызган видео буенча сорауларыбыз калды әле. Авыл халкы болай да хәләл көчен куеп, тормышын бәрәкәтле итеп алып барырга җаны-тәне белән тырыша. Инде ел башыннан сөт бәяләре 3–4 сумга төшүне дә тешен кысып түзә ул. Күп очракта сөт бәяләре төшүдә халыкның үзен гаепләп калдырырга тырышалар. Инде хәзер сөт җыючылар ниндидер аңлаешсыз «уен» уйный башлаганнар булып чыгамы?

Зөһрә САДЫЙКОВА

«ЖУРФАК» ТУГАН КӨН

Җәһәт әңгәмә

Журналистлар, бигрәк тә каләм осталарын әзерләүчеләр өчен 24 март – истәлекле көн: 1962 елда нәкъ шушы көнне РСФСР Мәгариф министрлыгы боерыгы нигезендә, Казан дәүләт университетының тарих-филология факультеты составында журналистика кафедрасы оеша. Шул уңайдан КФУның милли һәм глобаль медиа чаралары кафедрасы мөдире Васил ГАРИФУЛЛИН белән без хатирәләрне дә барладык, хәзерге көн турында да сөйләшеп алдык.

– Чынлап та, университетта журналистика белеме бирә башлауга алты дистә елдан артып китте. Мин үзем дә шушы бүлектә тарих-филология факультеты студенты буларак укый башлаган идем, укуны исә филология факультеты составында тәмамладым. Соңрак журналистлар филфактан да аерылып чыктылар, мөстәкыйль журфак булып яшәделәр. Факультет үсте, киңәйде, безгә социология һәм психология белгечлекләре кушылды. Бу үзгәрешләр барысы да легендар җитәкчебез Флорид ага Әгъзамов кул астында узды. Ул журналистика кафедрасын 1972 елдан 1998 елга кадәр җитәкләде. Университетка күчеп килгәнче Флорид ага «Социалистик Татарстан» газетасының баш мөхәррире урынбасары була, Мәскәүдә иҗтимагый фәннәр академиясенең аспирантурасын уңышлы тәмамлый, кандидатлык диссертациясен яклый. Татар журналистикасының торышын анализлауга багышланган берничә китап бастырып чыгара. Шул чордан башлап, ул үз тирәсенә теоретиклардан да, журналистиканың танылган практикларыннан да торган югары профессиональ педагогик коллектив туплый. Сиксәненче елларда бирегә егермедән артык практик журналист белем бирде, шулай итеп студентлар аудиториясенә редакция атмосферасы сеңдерелде. Бер яктан, студентлар журналистлар белән аралашса, икенче яктан, практикларга яшь буынның фикер-омтылышларын белеп тору өчен яхшы тәҗрибә булды бу. Журналистика кафедрасы Казан предприятиеләренең күптиражлы басмалары редакцияләре белән актив хезмәттәшлек итте. Алар базасында уку газеталары чыгарылды. Студентлар планлаштыру, макетлау һәм верстка күнекмәләрен өйрәнде.

Флорид Имамәхмәтович илдә беренче тапкыр уку планнарына һәм дәресләр расписаниесенә, җәйге практикаларга өстәмә рәвештә, студентларның уку семестры дәвамында да редакцияләрдә эш көне кертелүенә ирешә алды.

Соңрак үземә дә аның кулыннан җитәкчелек дилбегәсен алып, факультет белән җитәкчелек итәргә туры килде. Туксанынчы еллар азагы һәм XXI гасырның беренче дистә еллыгы иде бу.

> Әлеге чорны мин һич курыкмыйча журфакның «алтын чоры» дип әйтә алам. Студентларыбыз саны бермә-бер артты, яңа белгечлекләр, профильләр барлыкка килде, журналистларны төрле юнәлештә махсуслаштыручы өч яңа кафедра ачылды, укыту-җитештерү лабораторияләре оештырылды, матди-техник яктан зур алга китеш булды, Идел буе төбәгендә беренче буларак аспирантура ачылды, диссертацияләр яклау советы оештырылды. Кыскасы, заман таләпләренә җавап бирә алырдай белгечләр әзерли башлау өчен ныклы база булдырылды бу чорда.

:: Бүген ничек яшәп ятасыз?

– Шунысы куанычлы: остазларыбыз мирас итеп калдырган традицияләр бүген дә уңышлы дәвам итә. Элекке журналистика факультеты базасында хәзер Журналистика һәм медиакоммуникация югары мәктәбе уңышлы гына эшләп килә. Хәзер бездә басма матбугат, мультимедиале журналистика, телевидение, медиакоммуникацияләр, җәмәгатьчелек белән элемтәләр юнәлешләре буенча бакалавриатта ике меңгә якын студент белем ала. Бик күп иҗади медиапроектлар гамәлгә ашырыла, университетның телевизион каналы тапшырулары да нигездә студентларыбыз тырышлыгы белән әзерләнә.

«Татар-информ»

:: Хәзер белгечләргә кытлык бармы ул? Сезгә мөрәҗәгать итәләрме?

– Хәтерләсәгез, без укыган сиксәненче елларда көндезге бүлеккә ел саен ике төркем студент кабул ителә иде. Җәмгысы – 50 кеше. Ә без быел гына да бакалавриатның беренче курсына 500гә якын студент кабул иттек! Аерманы сизәсезме? Әле өстәвенә магистратурага 70 кеше кабул ителде. Ник шулкадәр күп дисәгез, безнең университет хәзер федераль вуз статусын йөртә һәм анда укучыларның күпчелеген Россиянең төрле төбәкләреннән һәм чит илләрдән килгән студентлар тәшкил итә. Хәзер беренче курста чит ил балаларыннан гына торган 27 кешелек бакалавриат төркеме бар. Магистратурадагы 24 кешелек төркемдә – тулаем Кытай Халык Республикасы гражданнары. Журналистика бүлегендә белем алучылар барысы да диярлек килешү нигезендә үзләре түләп укый. Бердәнбер искәрмә бар: татар төркемендә укучы милләттәшләребез барысы да федераль бюджет хисабына яки дәүләт, я аерым оешмалар грантлары акчасына белем ала. Әйтик, «ТНВ» компаниясе бүген татарча белем алучы биш студентыбызга үз хисабына белем бирә.

Болар барысы да журналист кадрларга ихтыяҗның зур булуын дәлилли. Медиа өлкәсе киң һәм тирән белемле, заманча күнекмәләргә ия булган белгечләргә бик тә мохтаҗ.

:: Укырга керергә, журналист булырга хыялланучылар күпме?

– Яшьләр арасында кечкенәдән иҗат белән шөгыльләнеп, журналист һөнәрен сайлаучылар күп. Профессиональ журналистик кадрларны әзерләүнең хәзерге мантыйгы да студент-журналистларны мәктәп эскәмиясеннән үк сайлап алу һәм аларны алдан әзерләүне таләп итә. Әйтик, Казан университеты чирек гасыр «Алтын каләм» республика балалар-яшүсмерләр матбугат фестивален оештыруда актив катнаша. Анда ел саен республиканың барлык районнарыннан берничә мең укучы катнаша. Йомгаклау турында җиңүчеләр КФУның журналистика бүлегенә ташламалы рәвештә керү хокукын ала. «Алтын каләм»нән чыккан кешеләр – бүген журналистиканың барлык жанрларында, шул исәптән медиа системасының иң югары технологияле өлкәләрендә эшли белүче, иң популяр журналистлар, каләм һәм микрофон осталары. 2015 елдан республикада медиа белем бирү өлкәсендә тагын бер конкурс гамәлгә куелды. Бу – Язучылар берлеге оештырган «Илһам» бөтенроссия конкурсы. Анда татар телендә иҗат итүче яшь язучылар һәм журналистлар катнаша. Казан федераль университеты, әлеге конкурсны гамәлгә куючыларның берсе буларак, медиа белеме бирү юнәлешләре өчен конкурста катнашучыларның иң лаеклыларын сайлап ала. КФУ каршында шулай ук гомуми белем мәктәпләренең, гимназия һәм лицейларның өлкән сыйныф укучылары өчен яшь журналист мәктәбе эшли.

:: Бүгенге студент нинди ул? Нинди әзерлек белән килә?

– Кызганычка, БДИ системасы мәктәп эскәмиясеннән үк булачак студентның дөньяны танып-белү киңлеген дә, тирәнлеген дә киметүгә китерде, бу система бигрәк тә безнең өчен мөһим булган социогуманитар белемнәрне, дөнья мәдәниятен, әдәбиятын үзләштерүне шактый сыегайтты. Шул ук вакытта бүгенге студент технологик белемнәр белән яхшы коралланган, кирәкле мәгълүматны бик тиз таба.

> Шунысын да әйтим: татар бүлегендә укучы студентларыбыз белемгә омтылыш, максатчанлык дәрәҗәләре белән башкалардан бер дә калышмый. Әле быел гына «Милли медиа чаралары» профиле буенча бакалавриатны тәмамлаган 12 татар студентының 8е университеттан кызыл диплом алып чыкты. Бу – югары сыйфат күрсәткече.

:: Хәзер журналистика мәктәбен тәмамлаучылар кайда эшләргә хыяллана? Теләкләре тормышка ашамы?

– Студентларыбызның күпчелеге эш урынын укыган чорда ук сайлый башлый. Моның өчен төрле редакцияләрдә практика үтеп карыйлар, үзләрен яхшы яктан күрсәтергә тырышалар. Быел татар журналистикасы бүлеген тәмамларга җыенучы дүртенче курс студентларының күпчелеге исә Татарстанның хөкүмәт гранты буенча белем алды һәм алар укырга кергәндә үк аерым редакцияләр белән килешү төзегән иде. Алар шул редакцияләрдә практика уздылар һәм эшкә дә шунда китәчәкләр.

:: Журналистика мәктәбенә нинди яңалыклар кертер идегез?

– Югары белем өлкәсендәге кардиналь үзгәрешләр чорында заман таләпләре белән бергә элекке традицияләр, шул исәптән БДИ урынына мәктәпләрдәге традицион чыгарылыш имтиханнарын алу гамәлгә кертелсен иде. Шулай ук минем бик зур хыялым – милли кадрлар әзерләүгә игътибарны көчәйтеп, студентлар кабул итүгә федераль бюджеттан бирелә торган урыннар саны арттырылсын, ягъни теләгән барлык балаларга да бушлай белем алу мөмкинлеге тудырылсын иде. Шулай ук Татарстаныбызда милли журналистика өчен милли кадрлар булдыруга юнәлдерелгән даими максатчан программа төзелсен иде. Бу мәсьәләдә һаман да Мәскәү күзенә карап, изгелек өмет итеп утыру дөрес түгел, минемчә.

Әңгәмәдәш – Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен хезмәт ветераны **Богданчиков** Николай Алексеевич, хезмәт ветераны **Хәйруллин** Рәхимҗан Хәернас улы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының сугыш һәм хезмәт ветераннары җирле иҗтимагый оешмасы президиумы әгъзасы **Хәлимов** Хәлил Камил улы, хезмәт ветераны **Һидиятуллин** Җәлил Әмин улы, хезмәт ветераны **Чашин** Александр Михайлович, Бөек Ватан сугышы ветераны **Чуйков** Владимир Ильич, хезмәт ветераны **Шәмгунов** Роберт Шакир улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

«Россия почтасы» акционер җәмгыятенең «Татарстан почтасы» федераль почта элемтәсе идарәсе Саба районара почтамты Байлар Сабасы транспорт участогы йөк автомобиле йөртүчесе **Ганиев** Мулланур Мөхәммәтҗан улына, «Челтәр компаниясе» акционер җәмгыятенең «Казан электр челтәрләре» филиалы механикалаштыру һәм автотранспорт хезмәте башлыгы **Русаков** Николай Ивановичка, «Россия тимер юллары» ачык акционер җәмгыяте филиалы – Хәрәкәт белән идарә итү үзәк дирекциясе структур бүлекчәсе – Хәрәкәт белән идарә итү Горький дирекциясе структур бүлекчәсе – Әгерҗе тимер юл станциясенең поездлар турында мәгълүматны һәм документларны эшкәртү буенча өлкән операторы **Гусоргина** Екатерина Александровнага, «Россия тимер юллары» ачык акционер җәмгыяте филиалы – Хәрәкәт белән идарә итү үзәк дирекциясе структур бүлекчәсе – Хәрәкәт белән идарә итү Горький дирекциясе структур бүлекчәсе – Әгерҗе тимер юл станциясенең хезмәтне оештыру һәм нормалаштыру буенча әйдәүче инженеры **Мусина** Әлфирә Рафаил кызына **«Татарстан Республикасының атказанган транспорт хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Желтова Неля Гариф кызы Татарстан Республикасы адвокатлык кабинеты адвокаты **Желтова** Неля Гариф кызына, «Зеленодольск муниципаль районының юридик бюросы» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе **Пименова** Наталья Николаевнага, Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүгә, аларның әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучыларның хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы дәүләт инспекциясенең административ һәм суд практикасы бүлеге башлыгы **Эйдинов** Борис Григорьевичка **«Татарстан Республикасының атказанган юристы»** дигән мактаулы исем бирелде.

МАНТУНЫҢ КИРӘК ЧАГЫ

Җиде кат уйлап, бер кат кисәсе. Табиблар, баласының туберкулезга каршы тикшеренү узуына каршы булган ата-анага шушы киңәшне истә тотарга куша. Ник дигәндә, соңгы арада туберкулез белән авыручылар саны арта башлаган. Республикада гына түгел, дөнья күләмендә шул хәл.

istockphoto.com

Узган ел Татарстанда туберкулез йоктыручылар саны, алдагы ел белән чагыштырганда, 6,8 процентка арткан. Татарстан буенча Роспотребнадзор идарәсенең бүлек башлыгы Анна Алешина сүзләренә караганда, 14 районда (Арча, Әгерҗе, Әлки, Әлмәт, Буа, Югары Ослан, Биектау, Яшел Үзән, Кайбыч, Лениногорск, Мөслим, Нурлат, Теләче, Ютазы) бу күрсәткеч республика күләмендәге уртача саннардан да югарырак.

– Югары Осланда әлеге мәкерле чирне йоктыручылар саны республика буенча уртача күрсәткечтән – 2,2 тапкыр, Кайбычта 3 тапкыр күбрәк. Туберкулез белән авыручыларның күпчелеге –18–49 яшьлек кешеләр, – ди ул.

Дөрес, саннар артса да, Татарстанда туберкулез белән авыручылар ил күләмендәгеләр белән чагыштырганда 20 процентка азрак. 2021 елга кадәр дөнья күләмендә әлеге мәкерле чирне йоктыручылар саны ел саен якынча 2 процентка кими барган. Әмма шушы ел азагында инде саннар кисәк кенә арта башлаган. Республиканың туберкулезга каршы клиник диспансеры баш табибы Алексей Алексеев сүзләренә караганда, белгечләр моның сәбәбен әле дә булса аңлап бетерә алмый.

– Туберкулез дөнья күләмендә үлемкитем очракларына китергән иң төп ун авыруның берсе санала. 2021 елда дөньяда 10,6 миллион кеше туберкулез йоктырган. Бу, 2020 ел белән чагыштырганда, 4,5 процентка күбрәк. 2021 елга кадәр туберкулез йоктыру очраклары ел саен 2 процентка кими барды. Әмма ел азагында бу чирне йоктыручылар саны кисәк кенә арта башлады. Бәлки моңа пандемия йогынты ясагандыр. Әлегә бу сорауга төгәл генә җавап таба алмыйбыз, – ди табиб.

Белгеч үзе коронавирусны авырдан уздырган кешеләр флюорографияне даими рәвештә узарга тиеш дип саный. Ковид үпкәләрне зарарлый. Бу исә туберкулез пәйда булу куркынычын да бермә-бер арттыра.

Билгеле булганча, туберкулез – кешедән кешегә һава аша йога торган инфекцияле хроник авыру. Ул бик чыдам. Әйтик, авыру кешенең тирәсендәге бактерияләр кипкәннән соң да – ун ай дәвамында, караңгыда өч елга кадәр саклана. Алар авыруның киеме, көндәлек кирәк-яраклары, китапларда да бик озак саклана, дип кисәтә белгечләр.

– Шуңа күрә авыру кеше белән контактта булучылар тиз арада табибка күренергә тиеш. Риск төркеменә керүчеләр, балалар, азык-төлек белән эшләүчеләр, хроник үпкә, сидек юлы, ашказаны эчәк-тракты авырулары булган кешеләр флюорографияне елга бер тапкыр уза. ВИЧ инфекцияле, психиатрия оешмаларында исәптә торучылар бу тикшеренүне елга ике тапкыр узарга тиеш, – ди Анна Алешина.

Бу чирне мәкерле диюләре дә юкка түгел. Ник дигәндә, ул еш кына үзен берниндиди билгеләр белән дә сиздерми – яшерен генә азып ята бирә. Олыларда ачыкланган туберкулез – 50 процент очракта, кечкенә балаларда тулысынча берниндди билгеләрсез уза икән.

– Гадәттә, балада туберкулез билгеләре үсмерлек чоры башлангач кына күренә башлый. Андый чакта ул тиз арый, хәлсезләнә, зарлана, башы әйләнә, температурасы күтәрелә. Шуңа күрә балалар, үсмерләр туберкулезга ел саен тикшеренү узарга тиеш, – ди Анна Алешина.

Узган ел республикада 972 кеше туберкулез йоктырган. Шуларның 33е – бала. 3,5 меңнән артык бала туберкулезга каршы тикшеренү узмаган. Шуларның 17 проценты бүген мәктәп, балалар бакчаларына йөри.

– Мондый балалар булган белем бирү оешмаларында туберкулез таралу куркынычы бермә-бер арта. Форсаттан файдаланып, баласын туберкулезга тикшертүгә каршы булган ата-аналарга мөрәҗәгать итәсем килә. Манту яки диаскинтест – балада туберкулез барлыгын-юклыгын ачыкларга ярдәм итүче бердәнбер ысул. Уңай нәтиҗә бирсә, ата-ана баласының сәламәтлегенә тагын да игътибарлырак булырга, аны бер ай дәвамында фтизиатрга күрсәтеп торырга тиеш. Мондый тикшеренү узмаган бала белем бирү оешмасына кертелми, – ди Анна Алешина.

Кертелмәү дигәннән, соңгы елларда белгечләр безгә читтән килеп эшләүчеләрне дә күпләп тикшерә башлаган. Узган ел белгечләр Татарстанда яшәп эшләүче 64 меңнән артык мигрантны тикшергән. Бу, алдагы ел белән чагыштырганда, 20 меңгә күбрәк.

– Шуларның 29ында туберкулез барлыгы ачыкланды. Аларның бер өлеше бездә калды, калганнары дәвалану өчен туган якларына кайтып китте. Соңгы елларда бездә тикшеренгән чит ил кешеләре арасында туберкулез ачыклану очраклары ике тапкыр диярлек кимеде, – ди Алексей Алексеев.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЛАРЫ

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык икенче утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы кырык икенче утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.
2. «2022 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге нәтиҗәләре һәм Татарстан Республикасында бала хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләренең үтәлеше турында» Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил докладлы.
3. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 405-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
4. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 395-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
5. «Татарстан Республикасы аерым закон актларының үз көчен югалтуын тану турында» 402-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
6. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 13^1 һәм 21 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 401-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
7. «Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» 400-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
8. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының 10^4 һәм 13 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 412-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
9. «Татарстан Республикасы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2023 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 404-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
10. «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында булган мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 391-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).
11. «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 13 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 397-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
12. «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына һәм «Татарстан Республикасы территориясендә энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 406-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
13. «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 408-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
14. «Татарстан Республикасы Экология кодексының 135^5 статьясына үзгәреш кертү турында» 398-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
15. «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына һәм Татарстан Республикасы Экология кодексының 2 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 409-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
16. «Татарстан Республикасы Экология кодексына һәм «Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 9 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 407-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
17. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 399-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
18. «Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 411-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
19. «Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен яклауның аерым чаралары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 403-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
20. «Татарстан Республикасында матди булмаган мәдәни мирас турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 410-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
21. «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» Федераль законның 22 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.
22. Сирәк (орфан) авырулардан интегүче затларны дарулар белән тәэмин итү тәртибе турында Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе В.В. Володинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мөрәҗәгате хакында.
23. Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы каршындагы Яшьләр парламентында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкиле турында.
24. Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең 2022 елда үз эшчәнлеге нәтиҗәләре турында доклады.
25. Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе эшчәнлеге турында мәгълүмат.
26. «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законга үзгәреш кертү хакында» 288225-8 номерлы федераль закон проекты турында (коррупциягә каршы көрәш турындагы законнарны камилләштерү өлешендә).
27. «Россия Федерациясе Конституция Суды турында» Федераль конституциячел законның 18 статьясына үзгәреш кертү хакында» 293645-8 номерлы федераль конституциячел закон проекты турында (федераль законнарда кулланыла торган төшенчәләрне унификацияләү өлешендә).
28. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 293721-8 номерлы федераль закон проекты турында (балалар белән эшләү һәм яшьләр хокукларын гамәлгә ашыру өлкәсендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне төгәлләштерү өлешендә).
29. «Россия Федерациясе Җир кодексының 39^{11} статьясына үзгәреш кертү турында» 287036-8 номерлы федераль закон проекты хакында» (җир кишәрлеге бирүдән баш тартуның өстәмә нигезләрен билгеләү өлешендә).
30. «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» Федераль законның 3^7 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 286758-8 номерлы федераль закон проекты турында» (гражданнарның гаражлар урнашкан җир кишәрлекләренә хокук алу мәсьәләләрен хокукый җайга салуны камилләштерү өлешендә).
31. «Балалы гаиләләргә дәүләт ярдәменең өстәмә чаралары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 222349-8 номерлы федераль закон проекты турында (өстәмә дәүләт ярдәме чараларына хокукы булган барлык затларга ана (гаилә) капиталы акчаларын тупланма пенсия булдыруга җибәрү хокукын бирү хакында).
32. Төрлесеннән.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 23 марты
№ 1878-VI ДС

Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары итеп өч елга түбәндәгеләрне сайларга:

Татарстан Республикасы Әгерҗе суд районы буенча:
2 нче суд участогына – Трегулов Айдар Раил улын;
Татарстан Республикасы Алексеевск суд районы буенча:
1 нче суд участогына – Хөснуллина Регина Марс кызын;
Татарстан Республикасы Лениногорск суд районы буенча:
1 нче суд участогына – Гатин Рамил Кыям улын;
Татарстан Республикасы Чистай суд районы буенча:
4 нче суд участогына – Садыйкова Ангелина Эдуард кызын.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 23 марты
№ 1879-VI ДС

«Ватаным Татарстан» газетасының махсус проекты Татарстанда яшәүче төрле милләтләрнең традицион уен кораллары белән таныштыра. Аның чираттагы чыгарылышын КУРАЙга багышлыйбыз. Әлеге уен коралының Җир шарында яшәүче 120ләп төрле халык арасында таралуы билгеле. Һәр халыкның – үз курае. Бүген без татар курае һәм аның үзенчәлекләре турында сөйләшербез.

Милли аккорд

МАХСУС ПРОЕКТ

КУРАЙ ЯСАУ ОСТАСЫ РАФАЭЛЬ ГАЙЗЕТДИНОВ:

«ИҢ СӨЕНДЕРГӘНЕ – БАЛАЛАРНЫҢ КЫЗЫКСЫНУЫ»

Татар кураеның язмышы кем кулында? Өметлеме ул? Аның абруен күтәрү – кемнең бурычы? Музыкант, курай ясау остасы Рафаэль ГАЙЗЕТДИНОВ белән әнә шулар турында сөйләштек.

:: Курай ясарга кемнән өйрәндегез?

– Үзлектән өйрәндем. Ифрат Хисамовның курай ясарга өйрәтә торган китабы бар иде, иң элек шуннан карап ясадым. Ләкин барып чыкмады – ясаган кураем уйнамады. Шуннан соң, бу китапны читкә куеп, үзем җайлый башладым. Музыкант булгач, барын да чамалыйсың бит. Ярыйсы гына сыйфатлы курай килеп чыкты. Аны Ринат Мөхетдиновка да күрсәттем әле. Уйнап карагач, ул да ошатты. Ул чакта аның Түбән Камада эшләгән мәле иде. Шуннан миңа 750 курай ясарга куштылар. 3,5 айда ясап тапшырдым. Тәҗрибә юк ул чакта, тизлекне әйтмим дә инде. Ике киявем ярдәм итте. Менә шуннан башланды инде барысы да.

> Мин ясый башлаганчы, курайны «чаңгы таягы» дип атыйлар иде. Нинди дә булса бәйгеләрдә курайда уйныйлар икән, «Бу бит инструмент түгел!» – дип кире бордылар.

:: Курай ясау серләрен өйрәнергә теләүчеләр, сездән соң бу һөнәрне дәвам итәрдәй осталар бармы?

– Үзем курай ясау белән 20 еллап шөгыльләнәм. Хәзерге вакытта өченче укучымны әзерлим. Шуларның икесе – рус милләтеннән. Дөресен генә әйткәндә, руслар күбрәк тә кызыксына әле.

:: Ә курайчылар, курайда уйный белүчеләр күпме?

– Күп. Мин саткан курайлар гына да 16 меңнән артып китте. Ихтыяҗ бар. Иң сөендергәне – балаларның кызыксынуы.

Курай ясау белән шөгыльләнә башлаган елларда профессиональ курайчыларны бергә җыеп, зур гына фестиваль оештыру тәкъдиме белән чыккан идем. Ул чакта ук моңа ихтыяҗ бар иде. Әмма Мәдәният министрлыгы бу уемнан кире кайтырга мәҗбүр итте. Алар да оештырмады, минем дә күңелем төште… Соңгы елларда милли мәдәниятләр, гореф-гадәтләр турында еш ишетәбез, бу юнәлешкә игътибар бирелә кебек. Әмма шул ук вакытта берни дә үзгәрми. Рөстәм Миңнеханов әле шушы көннәрдә генә Татарстанда 1500дән артык һөнәрче барлыгын һәм аларны Халыклар дуслыгы йорты «түбәсе» астына кертергә кирәклекне әйтте. Димәк, бүгенгә кадәр 1500 кешегә тиешле игътибар бирелмәгән. Ярый ла соң минем үз остаханәм бар. Билгеле, барын да үз акчама булдырмадым – ярдәм итүчеләр табылды. Әмма кайберәүләрнең мондый мөмкинлеге юк бит.

Автор фотосы

:: Рафаэль абый, сез ясаган курай күпме тора?

– Төрлесе бар. Күптән түгел генә мин курайны тик агачыннан да ясый башладым. Аның технологиясе катлаулырак, материалы да шактый кыйммәтле. Андый курай 3000 сум тора. Җиз курайлар 1200 сумнан башлана. Тональлегенә карап, бәясе үзгәрә. Әмма минем инде күптән бәяләрне күтәргәнем юк. Гәрчә кайберәүләр миннән ике мәртәбә кыйммәткә сатса да.

:: Курай ясау – керемле кәсепме?

– Юк. Дөресен генә әйткәндә, ике-өч мәртәбә туктарга кирәк дигән ният бар иде. Моны аңлагач, миңа грант бирделәр. Ул грант акчасына станокларымны арттыргач, күңелем үсте дә тагын тотындым инде *(көлә)*.

:: Курайның абруен ничек күтәрергә?

– Җитәкчелектән тора ул. Мин бу урында Башкортстанны мисал итеп китерер идем. Билгеле, башкортлар да курайны үзләре уйлап чыгармаган. Әмма заманында Мортаза Рәхимов аның абруен бик күтәрде. Музыка мәктәпләренә, уку йортларына, мәдәният үзәкләренә курайда уйнарга өйрәтүне мәҗбүри итеп куйды. Татарстанда да мәҗбүри төсмер өстәлсә, бер дә начар булмас иде. Курай – татарның җаны бит ул! Гади генә уен коралы булып тоелса да, күпме моң сыйган аңа. Аның мөмкинлекләре дә искиткеч киң бит. Югалтмасак иде кураебызны…

:: Аның язмышы кем кулында?

– Бүген зур масштабта курай ясаучылар юк диярлек. Курай да – әлеге дә баягы энтузиастлар кулында. Әмма алар да бик күренми. Ясап карыйлар да туктыйлар. Шуңа да язмышын бик өметле дип әйтә алмыйм…

P.S. Без килгәндә, Рафаэль Гайзетдиновның укучысы да остаханәдә мәш килә иде. 35 яшьлек Казан егете Илнур Халиков моңарчы бөтенләй башка өлкәдә эшләгән. «Элекке эшемне ташлап, Рафаэль абый янына килдем. Инструмент ясау – иҗат, сәнгать бит ул, шунысы ошый», – диде ул безгә. Хәзерге вакытта үзе дә остаханә өчен бина җиткерә икән. Остазы исә укучысы белән горурлануын һәм аңа зур өметләр баглавын яшерми.

РАФАЭЛЬ ГАЙЗЕТДИНОВ ОСТАХАНӘСЕННӘН ВИДЕОРЕПОРТАЖ

МАТУРЛЫККА ӨНДӘҮ

Укытучым Фарил абый безне иң элек курайда уйнарга өйрәтә иде. Хәзер генә аңлыйм: музыка дөньясы белән бала арасындагы күпер булган икән ул. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Фарил Дөлмиев инде өч дистә елга якын балаларда уен коралларына мәхәббәт тәрбияли. Аның белән без тәрбия өлкәсендә курайның роле, аның киләчәге турында сөйләштек.

– 1995 елда авылга (Мамадыш районының Кече Кирмән авылы. – **Авт.**) кайткач, иң элек балаларны курайда уйнарга өйрәтә башладым. Моның сәбәпләре күп һәм төрле. Бердән, балалар бакчасына йөрүче, я булмаса, кечкенә сыйныфларда укучы балалар өчен кулга тотып уйнарга җиңел инструмент ул. Бәясе дә әти-әниләрнең кесәсенә сукмый. Аннан, балаларның сәламәтлеге өчен дә файдасы бихисап – курайда уйнау тын юлларына файдалы. Ә иң мөһиме – бала тырышлыгының нәтиҗәсен тиз арада күрә һәм тагын да ялкынланып өйрәнә башлый. Курайда уйнаулары камил дәрәҗәгә җиткәч, башка уен коралын үзләштерә башлыйлар. Бу шулай ук – үзенә күрә стимул, – дип сөйләде ул.

Кызыксынулары булган балаларның урамда йөрергә дә вакыты калмый бит. Өстәвенә Фарил Дөлмиев, «Сандугач» ансамблен оештырып, аларны төрле шәһәрләрдә уза торган бәйге-фестивальләргә йөртә башлый.

– Балалар белән юлда йөрү искиткеч җаваплы булу белән беррәттән, бик мавыктыргыч та. Алар үзара аралашырга, олыны – олы, кечене кече итәргә өйрәнә, башка җирдә яшәүче яшьтәшләре белән очраша, булган сәләтләрен күрсәтә, – ди әңгәмәдәшебез бу турыда.

Хәзерге вакытта Фарил Дөлмиев Мамадышның «Квантум» үзәгендә 13 балага курайда уйнау серләрен өйрәтә.

– Авылда балалар бик кимеде. Әмма ничәмә-ничә буын авыл балаларын музыка белән «дуслаштыра» алуыма бик сөенәм. Белгәнне өйрәтәсе килү көчле булгач, шәһәр балалары белән дә эшләп карарга булдым. Шөкер, элекке укучыларым мине моннан да эзләп тапты: хәзер аларның балаларын өйрәтәм. Шунысы да куандыра: курай түгәрәгенә әти-әниләренең теләге белән генә түгел, каяндыр үзләре ишетеп тә килгән укучыларым бар, – ди ул. – Хәзер бит замана балаларыннан зарланырга яраталар. Ә мин элеккеге укучыларым белән алар арасындагы аерманы күрмим. Әйе, хәзер аларның барысының да кулында телефон. Аерма шунда гына.

Ничек кенә булса да, курайның киләчәге өметле булачагына ышана укытучы.

– Курай бит ул – күңелдәгене көйләп бирә торган уен коралы. Аның тавышын тыңлаганда татар язмышы күз алдына килә. Моны аңлаган һәм башкаларга да аңлата алган кешеләр булганда, киләчәге дә булыр, миңа калса. Ә курайда уйнарга өйрәтүчеләр, шөкер, җитәрлек. Билгеле, бу өлкәдә эшләр өчен чын «фанатик» булырга кирәк. Авырлыклары күп чөнки. Әмма мин бу эшчәнлекне матурлыкка өндәүгә тиңлим. Музыка белән дус булган балалар һәрвакыт башкалардан бер баш өстен була.

Бу – кызык!

- «Курай» атамасы «кура көпшә» сүзеннән килеп чыккан.
- Курайда уйнау сулыш алу системасын ныгыта.
- Курайның озынлыгы 120–180 миллиметрдан 450–1000 миллиметрга кадәр була.
- Әмирхан Еники «Курай» хикәясендә әлеге инструмент турында болай дип яза: *«Белмим, яшьтән үк тыңлап өйрәнгәнгә күрәме, миңа ясалма курайга караганда кырда үскән табигый курай якынрак та һәм тансыграк та иде. Дөресен генә әйткәндә, күптән инде мине бер нәрсә гаҗәпләндерә: ни өчен табигый курай бездә юк, ни өчен ул, әйтик, башкортларда сакланган да, бездә сакланмаган?.. Бик сирәк кенә очраган безнең курайчылар йә тимер, йә җиз курайда уйнаганнар. Бәлки, кеше кулы белән ясалган бу курайлар тегe ялан кураена караганда әйбәтрәктер, курай сәнгатендә үзенә күрә бер алга китештер?.. Ихтимал, шуның өчен дә ясалма курай табигый курайны гамәлдән кысып чыгаргандыр?..»*

БЕЛГЕЧ СҮЗЕ

Геннадий МАКАРОВ, сәнгать белеме кандидаты, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Казан дәүләт консерваториясе доценты

Курай – татар халкының иң борынгы һәм яраткан милли коралларының берсе.

Татарларның төрле этнографик төркемнәрендә курай коралының үзенчәлекле параметрлары бар. Казан тирәсендә яши торган татарларда ул – ике уен тишемле һәм сызгырту җайланмасы булган, чикләвек агачыннан эшләнгән курай төре. Иделнең уң ягында яшәгән мишәрләрнең этник төркемнәрендә шундый ук курай коралын **«гүрәй»** дип атыйлар. Татарларның Кама елгасының сул ягында (көньяк-көнчыгыш Татарстан) яшәүче татарлар элек курайны кура көпшәсеннән ясаганнар. Ике уйнау тишеме булган бу озынча коралны **«нугай курай»** дип атаганнар. Әлеге атама барлыкка килүенең аңлатмасы да бар. Алтын Урда таркалган чордан алып XVII гасыр уртасына кадәр әлеге җирләр бер үк вакытта Казан ханлыгы һәм Нугай Урдасы (Маңгыт йорты) юрисдикциясендә булуларына бәйле. Шуңа күрә бу төбәк татарларның этник сәнгатендә нугай мәдәниятенең элементлары шактый нык сизелә.

Татарстанның көньяк-көнчыгыш районнары кураен өйрәнү эшләре 1931 елда Солтан Габәшинең музыкаль-этнографик эзләнүләре белән башланып китә. Бу экспедиция барышындагы хисап язмасында халык курайларында уйнау сәнгате традицияләре тасвирлана һәм **Аксубай, Чирмешән, Лениногорск, Әлмәт, Азнакай** районнарының күп кенә авылларында курайчылар репертуарының ноталы материаллары да китерелә.

Бу традицияләр монда 1980 нче еллар башына кадәр дәвам итә. Мәсәлән, миңа Зәй-Каратай авылында яшәүче өлкән курайчы белән аралашырга туры килде. Аның белән 1979 елның 23 августында таныштым. Гыйльфанов Ибраһим Гарифулла улы (1908 елда туган) яшьтәшләреннән үрнәк алып, балачакта ук курайда уйнарга өйрәнә.

> Шулай итеп 1970 нче елларда татар авыл мәдәниятендә традицион курай әле бар иде, әмма курай сәнгатенә ихтыяҗ булмагач, бу сәнгать акрынлап сүнгән.

Моннан тыш бу төбәктә ике тишемле, башы туры итеп киселгән, тешкә терәтеп уйный торган кораллар турында хатирәләр шактый күп. Әмма бу курай төрендә уйнау катлаулырак булганга ул гамәлдән тизрәк чыккан. Төбәкнең аерым авылларында туры башлы курай турында танылган татар фольклоры җыючысы һәм курай сәнгатен тикшерүче Исмәгыйль Мусинның хезмәтләрендә теркәлгән. Әйтик, 1910–1952 елларда үзе җыйган уникаль курайлар коллекциясендә үсемлек сабагыннан ясалган көпшә курай да бар. Ул – курайчы Әлмәт районы Сталин исемендәге артель колхозчысы Корбанов Гали курае. Әле күптән түгел Лениногорск районының Сугышлы авылында мәгариф ветераны Минһаҗ ага Ямалиев (1914 елда туган) абыйсының хатыны Миңнури Кәлимулла кызы (1908–1978) туры башлы курайда уйнаганы турында сөйләде. Ул бик яхшы курайчы иде, мондый курайда тавыш чыгару ысулы башкортларның озын курайларына охшаш иде, ди. Бу традиция, Зәй һәм Шушма елгалары бассейны авылларында үткәргән этнографик тикшеренүләр материалларына караганда, киң таралган булган, әмма хәзерге вакытта сакланмаган.

Габәши әлеге традицияне Әлмәт районы Кама-Исмәгыйль авылында теркәгән. Ул, Шәмсикамал Хуҗина ике тишемле курайда уйнады, дип яза.

> Бүгенге татар фольклор сәнгатендә киң таралыш тапкан курай җиде тишемле. Мондый курайлар элеккедән үк Кама елгасының уң ягында урнашкан татар авылларының традицион сәнгатенә хас.

Бу корал диатоник тавыш тезмәле һәм якынча 30–35 см озынлыктагы, диаметры баш очында – 20 мм, ә түбән очында – 15 мм. Хәзерге вакытта музыкаль көнкүрештә бу төр курай өстенлек итә. Анда уйнарга өйрәнү ансатрак, диапазоны киң, ансамбльдә уйнау мөмкинлекләре күбрәк булу һәвәскәрләрнең игътибарын җәлеп итә.

Шулай итеп, татарларның төрле этнографик төркемнәренең курайда уйнау сәнгате шактый катлаулы һәм күптөрле. Хәзерге көндә курайларның башта телгә алган төрләрен дә торгызасы иде. Әлеге этник курайлар мәдәниятнең ныклы бер өлеше булсын иде.

Бер фото тарихы

Әлмәт районының Кама-Исмәгыйль авылында яшәүче курайчы әбиләр. Солтан Габәши фотосы. 1931 ел. Әлеге авылда курайда уйнау традициясе әле дә яшиме икән? Моны ачыклар өчен, авыл җирлеге башлыгы белән элемтәгә кердек. Кызганыч, курайда уйный белүчеләр авылда калмаган икән инде...

Лилия ГЫЙМАЗОВА әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар: ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5332 данә
Гомуми тираж – 15281 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 242

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+